**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ**
**НИЖНЕКАМЕНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ул.тральная ,дом 51, с.Нижняя Каменка, 423114

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ТҮБӘН КӘМИНКӘ АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

Үзәк урам, 51 нче йорт, Түбән Кәминкә авылы, 423114

тел./факс email: 8-(84396) 2-35-21. Nkam.Cmn.2@tatar.ru

№ 147 26 декабрь 2024 ел

КАРАР

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2019 елның 12 февралендәге №118 карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып, физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын билгеләү тәртибен Татарстан Республикасы территориясендә куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында» 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Түбән Кәминкә авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2019 елның 12 февралендәге №118 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктта:

- 2 абзацның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «гаражлар һәм машина урыннары, шул исәптән салым салу объектларында урнашканнары, Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына, Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата, шулай ук һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата».
- 3 абзацның 1 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Түбән Кәминкә авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе Халиков Р.Р